Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«24» ноябрь 2020 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Кизләү авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Киекле авыл җирлегенең Кизләү авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнарның, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Кизләү авылында су җыю скважиналарын тоту өчен, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту, таш, ватык кирпеч, грунт, вак таш, ком (сатып алу, ташу, җәю).

Кизләү авылында урамнарны яктыртуны оештыру өчен эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу.

Кизләү авылы зиратын төзекләндерү һәм сезонлы тоту (коймаларны ремонтлау, агач кисү, үлән чабу).

Кизләү авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, урнаштырылган гидрантларны ремонтлау) халыкның янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Кизләү авылында массакүләм һәм спорт чараларын оештыру һәм уздыру.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.А.Заһертдинова

Киекле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Ә. Заһертдинова